| | |
|---|---|
| СОВЕТ ЯНГУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢГУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

---

| | |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| «29» ноябрь 2024 ел | № 123 |

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге Советының 29.06.2022 ел № 51 «Мөлкәткә салым турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге Советының «Мөлкәткә салым турында» 29.06.2022 ел, № 51 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 пунктында, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата " сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат (pravo.tatarstan.ru) порталында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә гамәлдә була.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Яңгул авыл җирлеге Советы башлыгы — Р.Р.Гыйльфанов